ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2024 г.Казань № 660-106/тэ-2024

«ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 ел, №660-89/тэ-2023 карары белән билгеләнгән тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштерү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 19.12.2024 ел, №36-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2025 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2025 елга җылылык энергиясенә тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024 – 2028 елларга «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү турында» 14.12.2023 ел, №660-89/тэ-2023 карары белән

билгеләнгән тарифларны 2025 елга төгәлләштереп, кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 660-89/тэ-2023
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2024 № 660-106/тэ-2024
карары редакциясендә)

## Казан ш. «ТГК-16» АҖ кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукциял әнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1.1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 587,81 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1 841,86 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 841,86 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 162,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 1 588,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 1 943,07 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 1 943,07 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 559,15 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 1 559,15 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 2 101,62 | - | - | - | - | - |
| 1.1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 905,37 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 210,23 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 210,23 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 595,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 1 906,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 2 331,68 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 2 331,68 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 870,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 1 870,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 2 521,94 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге